ГУМАНИТАР ЯРДӘМ

Казаннан Лисичанск шәһәренә тагын биш йөк машинасы юл тотты

> 2

РӘСИМ САТТАРОВ:

«Банкирлыкка түгел, «балкүр»леккә омтылам»

> 2

ГОМЕР ДИСБЕСЕ

Татарстанның атказанган төзүчесе Мөхәммәт Гатиятуллинның тормыш кагыйдәләре

> 3

ЯШЬТӘН БӨГҮ

Лаеш районы Кече Елга авылында яшәүче Маһирә Шәвәлиева 7 ир бала үстергән

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 173 (28946) | Чәршәмбе | 23 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КЫШКА ӘЗЕРЛЕК

ЮЛЧЫЛАРНЫҢ БОРЧУЫ ЮК

470 мең тонна ком-тоз катнашмасы, 1148 данә техника. Республика юлчылары кышка тулысынча әзерләнеп беткән. Кар яуса да, боз яуса да, юлга чыгарга куркып торасы юк, дип ышандырды Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов. Юлга түшәлгән акчаны да санап күрсәтте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хөкүмәт йортында узган брифингта республикадагы юл эшләре программаларының үтәлеше һәм кышкы чорга әзерлек турында сөйләделәр. «Ел азагына кадәр Татарстанда федераль һәм төбәк дәрәҗәсендәге юл эшләренә 194 миллиард сум акча тотылачак. Бу – республика тарихында рекордлы саннар», – диде министр. Юлчыларның эше дә күз алдында. Татарстанда М12 югары тизлекле автомобиль юлы төзелеше дәвам итә. Яңа юл республиканың Кайбыч, Апас, Югары Ослан, Кама Тамагы, Лаеш һәм Питрәч районнары аша узачак. Югары тизлекле юлны 2024 елда төзеп бетерерләр дип көтелә. Республика аша аның озынлыгы 142 чакрым тәшкил итәчәк дип фаразлана. Быел әлеге төзелеш кысасында Татарстанга 101 миллиард сум акча бүлеп бирелгән.

Алга китеп булса да, министрдан яңа юлдан хәрәкәт итүнең бәясе турында да кызыксындылар. Фәрит Хәнифов исә, ашыкмаска киңәш итеп, мәсьәләнең икенче ягына төртеп күрсәтте. Аның сүзләренә караганда, югары тизлекле юл төзелеше барышында якындагы авыллар тирәсендәге җирле юлларга зыян килгән. Салалар арасындагы таш юл зур техникалар чаптырып йөрүгә исәпләнмәгән. Шуңа күрә йөзләгән чакрым юл таушалып беткән. «Проектны тормышка ашыру кысасында мондый юлларның барысы да тәртипкә китереләчәк», – дип ышандырды министр.

Ел башыннан бирле 52 чакрым озынлыкта төбәк дәрәҗәсендәге юллар төзелгән һәм үзгәртеп корылган. Моның өчен 3 миллиард сумнан артык акча тотканнар. Тагын шулкадәр чамасы акча гамәлдә булганын төзекләндерүгә сарыф ителгән. Социаль юнәлештәге программалар кысасында республика районнарында 150 чакрым юлга вак таш түшәлгән, 12 фермер хуҗалыгы юллы булган, тагын 14 бакчачылык ширкәтенә илтүче юлны тәртипкә китергәннәр. Татарстанда «Имин сыйфатлы юллар» проектын тормышка ашыру да дәвам итә. Аның кысасында быел юлларга 9 миллиард сумнан артык акча тотылган.

Башкалада да эш кайный. Быел Казанда 127 мең урам яктырган, өстәмә 5 мең машина кую урыны барлыкка килгән. «Агымдагы елда Казанда юл төзелешенә 25 миллиард сум акча бүлеп бирелде, – диде Казан башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Игорь Куляжев. – Шәһәр үсә, шуңа күрә юлларга кытлык зур. Бигрәк тә шәһәр яны бистәләрендә юл салып бетерергә дә өлгермибез, биредә инде яңа урамнар «үсеп» чыга».

«Казанга керү-чыгу юлларында «бөке»ләр бетәчәкме?» – дип тә сорадылар җитәкчедән. Горький шоссесы ягында юллар алга таба киңәячәк, дип җавап бирде ул. Биредә эш бара инде. Ә менә Мамадыш тракты юлы әлегә ничек бар, шулай калачак. Вазгыятьне азмы-күпме җиңеләйтү өчен, биредә светофор урынына борылып төшү юллары салырга ниятлиләр. Тиздән Казанның тагын бер «капка»сы – Лаеш районының Сокуры авылы тирәсендәге «бөке» дә куркыныч төш булып кына истә калачак дип фаразлана. Билгеле булганча, федераль проект кысасында әлеге авылны әйләнеп узучы юл салыначак. Тик шунысы да бар: төзелеш шәхси җир кишәрлекләре аша узачак. «Әлеге мәсьәләдә Татарстан Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә эш алып барыла. Зыян күрүчеләргә акчалата компенсация түләнәчәк», – диде Фәрит Хәнифов.

Соңгы арада юлларга бәйле тагын бер борчыган мәсьәлә: Казанда җәмәгать транспортына бәяләр 2 сумга арту-артмауга карата төгәл мәгълүмат юк. Мондый имеш-мимешләр бу атнада пәйда булды. Әйтүләренә караганда, юлда йөрү бәясе 2 сумга артачак. «Бу – һәр гаиләгә диярлек кагыла торган мәсьәлә. Шуңа күрә нинди дә булса карар кабул иткәнче, иң элек җентекләп уйларга кирәк», – диде министр.

Гамәлдәге юлларны кыш көне дә тәртиптә тотарга вәгъдә иттеләр.

– Без кышка әзер, – дип ышандырды Фәрит Хәнифов. – Кирәкле тоз-ком катнашмасы да, техника да, эшчеләр дә җитәрлек.

Узган елларда беренче кар явып күрсәтте инде. Казанда, мәсәлән, айлык норманың өчтән бере күләмендә кар яуган. «Юл хезмәтләре шәһәрдән 17 мең тонна кар чыгарды», – диде Игорь Куляжев. Аның сүзләренә караганда, башкалада явым-төшемнәргә каршы көрәшкә 74 мең тонна ком-тоз катнашмасы әзерләп куйганнар. «Карның күплеге түгел, ә аның туктамыйча ишеп явуы кыенлыклар китереп чыгарырга мөмкин», – диде җитәкче. Һава торышы якын арада ук кышка әзерлекне сынап карамакчы, ахры. Синоптиклар фаразларына ышансаң, алдагы көннәрдә буран һәм бозлы яңгырлар көтелә. Юлчыларга ышан, үзең кымшан, кыскасы.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Арзанлы машина алалар

Россиядә машина сатып алуга ташламалы кредит программасы 2023 елга кадәр озайтылды. Әлеге программа бездә җитештерелгән машинага, бәясенең 20 проценты күләмендә ташлама белән, кредит бирүне күздә тота. Ерак Көнчыгышта яшәүчеләр өчен ташлама тагын да күбрәк – 25 процент тәшкил итә. Программадан машинаны үз гомерендә беренче тапкыр сатып алучылар, балалы гаиләләр, дәүләт медицина һәм мәгариф оешмаларында эшләүчеләр файдалана ала.

«РИА Новости» агентлыгы язганча, моңа кадәр Президент Владимир Путин ташламалы автокредитны мобилизацияләнүчеләргә, контракт буенча хезмәт итүче хәрбиләргә, аларның хатыннары, балалары һәм ата-аналарына да бирү тәкъдимен хуплаган.

Сүз уңаеннан, июнь – сентябрь чорында Россиядә эшләп чыгарылган машиналарга ихтыяҗ 4,5 тапкыр арткан. Хәзер инде ике кредитның берсе шуңа туры килә. Барлык кредитларның яртысы диярлек (43 проценты) Lada автомобильләрен сатып алу өчен бирелә.

Үзебезнең курчак булсын

Балалар товарларын җитештерүчеләр яңа мультфильмнарның сабыйлар күңеленә хуш килгән әкият геройларын тиз генә эшләп, базарга чыгарырга тиеш. Дәүләт Думасы вице-спикеры Анна Кузнецова шулай дип белдергән. Аның әйтүенчә, узган елда илдә балалар өчен җитештерелгән товар 19 процентка артып, бер триллион сум тәшкил иткән. Шул рәвешле үзебездә эшләп чыгарылган мондый товар өлеше 27дән 34 процентка җиткән. Депутат сүзләренә караганда, 2024 елга бу сан 35 процент булырга тиеш.

Шул ук вакытта, аның әйтүенчә, Россиядә җитештерелгән уенчыклар күләме кибетләрдәге ассортиментның уннан бер өлешен генә тәшкил итә. Шуңа күрә вице-спикер җитештерүчеләрне үзебезнең яңа мультфильмнарны тизрәк «тотып алып», шулар буенча товарлар эшләп чыгарырга чакырган. Кузнецова яңа уенчыкларның гаилә кыйммәтләренә җавап бирергә тиешлеген дә искәрткән.

Котылу юлы бар

Россиядә 59,9 миллион кеше грипптан прививка ясаткан. Ил халкының 40,9 проценты бу. Гриппка каршы вакцинация барлык төбәкләрдә, шул исәптән Татарстанда да үткәрелә.

Роспотребнадзор хәбәренә караганда, ОРВИны, аденовирус кебек, респиратор вируслар китереп чыгара. Ләкин грипп вируслары өлеше дә артканнан-арта. Узган атнада илдә 70кә якын кешенең грипп йоктыруы ачыкланган. Чирләүчеләр арасыннан 70 процентының 2009 елгы H1N1 штаммын, ягъни дуңгыз гриппын йоктыруы билгеле булган.

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина әйтүенчә, республикада да әлеге куркыныч гриппның тәүге очрагы ачыкланган. Гомумән, ул хәзер сезонлы чиргә әйләнгән.

Һава көйсезлекләре

Татарстанда ике көн рәттән – бүген һәм иртәгә һава торышы нык бозыла. Гидрометеоүзәк кисәткәнчә, җепшек кар, бозлы яңгыр, пәнҗешәмбегә каршы төндә урыны белән бигрәк тә көчле явым-төшем көтелә. Шулай ук буран да булырга мөмкин. Юлларда – бозлавык, кар көртләре.

Синоптиклар искәрткәнчә, бозлы яңгыр электр чыбыклары һәм агачларның бозлануына, юлларда бик көчле бозлавыкка китерергә мөмкин. Шуңа күрә һәркайсыбыздан зур саклык сорала.

Моңа кадәр метеорологлар хәбәр иткәнчә, ай ахырына кадәр республикада тәүлеклек уртача температура нормадан 2 градуска түбәнрәк булачак.

Яңалык

Агач ипотекасы

АГАЧ ЙОРТЛАР САТЫП АЛУ ӨЧЕН СУБСИДИЯ БИРӘЧӘКЛӘР

Россия Хөкүмәтендә агач йортлар сатып алучылар өчен ярдәм чаралары әзерләнгән. Билгеле булганча, ташламалы программа 2018 елдан эшли башлаган иде.

Россия Хөкүмәте агач йортлар сатып алуга ташламаны субсидияләячәк. Агач йорт төзүчеләргә субсидияләр бирү өчен ел саен кимендә 300 млн сум акча юнәлдереләчәк. Әлеге мөмкинлектән файдалану өчен, төзүчеләргә берничә таләпне үтәргә кирәк. Шулар арасында:

– җитештерү куәтләренең Россиядә булуын раслау;

– агач йорт комплектларына куелган прайс (бәяләр) булу;

– сатып алучы белән килешүдә ташламаны раслау.

Субсидия заводта җитештерелгән 3,5 млн сумлык әзер агач комплектларга кагылачак. Шул ук вакытта эшмәкәрләр сатып алучыларга йорт бәясенә 10 процентлы ташлама тәкъдим итәргә тиеш.

– Мондый ярдәм чаралары, гамәлдә булган карарлар белән берлектә, кешеләргә үз торакларын булдыру өчен күбрәк мөмкинлекләр бирәчәк. Шулай ук бу завод җитештергән агач йортларга булган ихтыяҗны, эш урыннарын һәм производстволарда мәшгульлекне саклап калачак, – ди әлеге җәһәттән Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустин.

Росреестрның Татарстан буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, 2022 елда кадастр учетына 1955 яңа агач торак йорт куелган. Шуның яртысыннан артыгы – 1128е – авыл җирлекләрендә. Бакчачылык өчен билгеләнгән җирләрдә – 495 йорт.

Сүз уңаеннан, Россиядә хәрби хезмәткәрләрнең ихтыяҗ булмаган фатирларын (сүз запаска киткәндә бирелә торган фатирлар турында бара) башка төр категория кешеләргә бирергә җыеналар. Бу хакта закон проектын Дәүләт Думасының өченче укылышында кабул иттеләр.

Шул рәвешле Министрлар Кабинеты төбәк хакимият органнарына моны башкара алырлык вәкаләтләр бирәчәк. Фатирлар исә Бөек Ватан сугышы ветераннары, аларның гаиләләренә, Чернобыльдәге аварияне юк итүдә катнашучыларга, әлеге фаҗигадән соң инвалид калучыларга, инвалид бала тәрбияләүчеләрнең гаиләләренә тапшырылачак.

Еш кына хәрбиләр өчен билгеләнгән торак милекченең үлүе, тORактан баш тартуы яки башка җиргә күчү сәбәпле, буш тора. Моңа кадәр төбәк хакимиятенең әлеге биналарны кемгәдер тапшыру хокукы булмаган. Шул рәвешле әлеге йортлар файдаланылмаган.

«Татар-информ»

Сүзгә-сүз

Ольга КАЗАКОВА, Россия Дәүләт Думасының Мәгърифәт буенча комитеты рәисе:

Хезмәттән аерып, бала тәрбияләп булмый. Бездә хәзер балага, технология дәресеннән кала, бернинди эш куша алмыйсың. Совет заманындагы кебек сыйныф җыештыртырга да ярамый. Шуңа күрә күбесе маркетолог һәм блогер булырга тели дә инде. Ә икътисадка төзүчеләр, юл хезмәткәрләре, эретеп ябыштыручылар кирәк.

(«Парламентская газета»га әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – КЫШКЫ ЯЛ

«Меркатор» белгечләре Россия халкыннан кышкы ялны ничек уздырырга хыялланулары турында сорашкан.

Илнең башка шәһәрләренә бару	47%
Россиянең табигый истәлекле урыннарына бару	45%
Санаторий, курортта ял итү	41%
Шәһәрдән читтә ял итү (дача)	37%



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КРИЗИС БИЛГЕЛӘРЕ ЕШАЙГАНДА

Глобаль икътисад акрын гына зур кризиска таба шуып кереп бара. Зур державаларның рәсми статистикалары никадәр генә рецессия башлануын яшерергә тырышмасыннар, зур түнтәрелешнең билгеләре тышка бәреп чыга. Иң беренче чиратта чималга бәяләр төшү рәвешендә чагыла ул. Атна башында нефтькә бәя 85 доллардан түбәнгәрәк китте. Дөрес, «кара алтын»ның арзанаюы гарәпләр аны чыгаруны 500 мең баррельгә арттыралар икән дигән ялган хәбәр тәэсирендә булды. Согуд режимы ул хәбәрне фейк дип игълан итү белән, баррель яңадан өскә күтәрелде, әмма түшәме барыбер биек булып чыкмады: 87 доллар тирәсендә тирбәлә. Нигездә Кытай икътисадының акрынаюы чимал бәяләренең түбәнгә китүенә хезмәт итә. Дөрес, кытайлар әле рецессия турында сүз алып бармыйлар, әмма хәзерге үсеш темплары аларның бурычларын капларлык түгел. Кытай икътисадының тормозга басуы – башка партнерларның алардан товар сатып алуны киметү нәтиҗәсе дә. Эшкәртү станоклары һәм сәнәгать роботларыннан алып, кыйммәтле косметикага кадәр ихтыяҗ кими.

Япон икътисады да июль – сентябрь айларында минуска киткән. Бөекбритания рәсми рәвештә рецессия башлануын таныды. Лондонда чыгымнарны 30 миллиард фунт стерлингка киметергә, салымнарны 25 миллиардка арттырырга ниятлиләр. Бу хакта британ финанс министры Джереми Хант әйтә. Глобаль икътисадның төп уенчыларының берсендә дә хәл мактанырлык түгел. Евростат июнь аенда ук төзелешнең еврозонада 1,3 процентка кимүен әйткән иде. Гыйнвар – ноябрь айларында почта аша товар алдыру 11 процентка кимегән. «Алибаба» гиганты статистикасын игълан итеп тә тормады. Сингапур биржасында тимер рудасына фьючерслар бәясе 2020 елның февраленнән соң иң түбән дәрәҗәгә төшкән.

Евросоюзда банкрот компанияләр саны 16,3 процентка үскән. Иң күп бөлүчеләр – Венгриядә. Анда алар 110,6 процентка арткан. Испаниядә банкротлык үсеше – 66,1 процент. Күрсәткечләр бишенче ай рәттән начарая.

Швециядә торак бәяләре зур темплар белән түбәнгә китә. Илдә соңгы утыз елда күрелмәгәнчә фатирлар очсызланган. Бәяләр якынча 14 процентка түбәнәйгән һәм бу күренеш инде җиде ай рәттән дәвам итә.

Малын тир түгеп тапкан гади халык өчен бәяләр төшү начар түгел инде ул. Әмма глобаль икътисадта бу эшсезлек арту белән кайтаваз бирә. Бәяләр бит сатып алырга акча булмау сәбәпле түбәнәя. Акчасы барлар аны криптобиржаларга һәм башка финанс куыкларына тыкты. Ул куыклар хәзер шиңә генә түгел, шартлый да. Кешеләр FTX криптобиржасының банкротлыгыннан айнып та җитмәде, Genesis криптофирмасы үзенең банкротлык алдында торуын хәбәр итә. Цифрлы валюталар белән бәйле фирмаларның түнтәрелеше алда торган кризисның төп давыл хәбәрчесе булырга охшаган. Без бу хакта аерым язма бирергә җыенабыз.

Лидерларның киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим иткән идеяләре халыкта яклау тапмый, нәфрәт кенә тудыра. Франция Президенты Макронның бердәм дөнья хөкүмәте төзүгә чакыруына җавап итеп, бер хатын аның яңагына чалтыратты.

Россиядә

КӨМЕШ ИНСТИТУТЫ ЧАҢ СУГА

Криптобиржалар янган, цифрлы валюталарның бәясе чүпкә чыккан бу заманда чын кыйммәткә ия малларның бәясе арта. Көмеш институты (The Silver Institute) биржа фондларында көмеш запасларының кимүе хакында хәбәр итә. Үткән елда ук 48 миллион унция көмеш дефициты булган инде. Быел кыйммәтле металлның җитмәүчелеге 194 миллион унциягә җиткән. Кытлык сәнәгать җитештерүчеләренең бу металлны күпләп сатып алуы нәтиҗәсендә туа. Аңа дөньякүләм ихтыяҗ 16 процентка үсәчәк һәм 1,21 миллиард унциягә җитәчәк, дип фаразлыйлар. Вак инвесторларның, зәркәнчеләрнең көмеш коелмалар һәм тәңкәләр сатып алуы да 2022 елда рекордлы күләмгә җитәчәк. Автомобиль җитештерүчеләр әлеге металлны күпләп сатып ала башлаган. Дөрес, алар көмешнең бары тик 5 процентын гына кулланалар. Әмма ихтыяҗның үсүенә бу да нык тәэсир итә. Россиядә бер елга 950 тонна тирәсе көмеш табыла. Санкцияләр кертелгәнче, ил, көмеш экспортлаучылар арасында Мексика, Перу һәм Кытайдан гына калышып, 4 нче урында торган.

Барлык активларның һәм валюталарның да бәясе төшкән вакытта үз кыйммәтен чагыштырмача яхшы саклап калачак тагын бер металл бар. Анысы – алтын. Июнь ахырында G7 илләре Россия алтынын импортлауга тыю керттеләр. Евросоюз бу тыюга 21 июльдән кушылды. Хәзер Европа бездән алтын коелмалар да, зәркән эшләнмәләр дә сатып алмый. Август башында эмбаргога иң күп алтын запаслары туплаган Швейцария дә кушылды. Гадәттәгечә, Россиягә Кытай аркадашлык күрсәтте. 2022 елның июлендә Россиядән анда алтын озату, рекордлы рәвештә артып, 108,8 миллион долларга җитте. Бу июнь белән чагыштырганда – 8 тапкыр, үткән елның июле белән чагыштырганда 50 тапкыр күбрәк. 2022 елның февраленә кадәр исә Россия өчен төп алтын базары булып Бөекбритания тора иде.

Дөнья илләренең Үзәк банклары үз запасларын алтын белән актив тулыландыралар. Интуитив рәвештә һәркем алтынның киләчәк валютасы булачагын тоя. Бу яктан караганда, Россиягә дә алтын запасын арттыру отышлы булыр иде. Кәгазь валюталарга ихтыяҗ юк бит, алар болай да кирәгеннән артык.

Акчасын алтынга күчереп сакларга теләүче хосусый инвесторларга «Тинькофф» банкы ярдәмгә килә. Ул хәзер алтынын өйгә китереп, матрас астына куеп китәргә дә риза. Тик моның өчен кимендә ярты килолы коелмага заказ бирергә кирәк. 1,5 миллион сумнан артыграк бәягә. 12 килограммлы коелмалар да бар. Зур коелмага заказ ясасаң, китерү бушка. Фәкыйрьләргә исә банкка үзләренә барырга туры килә. Тик граммлы коелмаларга кытлык шул.

ЭШЛЕКЛЕ СӨЙЛӘШҮЛӘР

Татар эшмәкәрләре

Соңгы өч көндә республикада Россиянең 48 төбәгеннән һәм чит илләрдән 300ләп тирәсе татар эшмәкәре эш тәҗрибәләре белән уртаклашты, яңа хезмәттәшлек юлларын эзләде.

«Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумы быел унбишенче тапкыр уздырылды. Эре һәм урта бизнес вәкилләре, үзмәшгульләр беренче көнне Яшел Үзән районындагы икътисади зонага бардылар, очрашуларда татар оешмаларына керү мөмкинлеген карадылар. Моннан тыш, үзләре җитештергән продукцияне маркетплейс системасы аша төбәкләргә һәм чит илләргә сату мөмкинлеге белән дә таныштылар. Иң яшь эшмәкәр Башкортстаннан килгән иде. Аңа 24 яшь. Ә иң өлкән бизнес вәкиленә – 81 яшь, дип игълан иттеләр. Ул Мордовиядән килгән.

Форумның пленар утырышы Казанның «Бәшир Рәмиев исемендәге IT парк» технопаркында узды. Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның сәламләвен җиткерде. «Бүген Татарстан – Россиянең таяныч төбәкләренең берсе. Куәтле җитештерү комплексы һәм һөнәрендә иң югары осталыкка ирешкән кыр батырлары, киң үсеш алган инфраструктурасы, Россия Хөкүмәтенең һәм Президент Владимир Путинның ярдәме нәтиҗәсендә республика социаль-икътисади тотрыклылыгын саклап килә. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы һәм Бөтендөнья татар конгрессының 30 еллыгы уңаеннан уздырылган чаралар һәрвакыттагыча милләтара һәм динара татулыкны, гражданнар җәмгыятендә тынычлыкны саклауга омтылуыбызны бөтен дөнья алдында тагын бер кат раслады», – диелгән иде әлеге сәламләү хатында.

Россиядән һәм чит илләрдән килгән эшмәкәрләр үз эшчәнлекләре белән уртаклашты, яңа проектлары белән тыныштырды. «Иң мөһиме Татарстанда бизнес өчен барлык шартлар да тудырылган һәм безнең арада ышаныч бар, чөнки Татарстан – безнең кече Ватаныбыз һәм ата-ана йорты». Һәр кешенең диярлек чыгышында әлеге фикер кызыл җеп булып үрелеп барды.

Кемдер үз эшчәнлеге белән таныштырса, кемдер яңа проектларын тәкъдим итте. Әйтик, Төмән өлкәсе эшмәкәре, «Полимерпласт» җәмгыяте генераль директоры Ринат Гайсин республиканың Лаеш районында яңа завод ачарга теләвен белдерде. Тәкъдим ителгән проекттан аңлашылганча, әлеге бинага киләсе елның өченче кварталында нигез салыначак һәм 2024 елда эшли башлаячак дип планлаштырыла.

Иң хисчән, ихлас чыгыш Татарстан кызы, хәзерге вакытта гаиләсе белән Мурманск өлкәсендә яшәүче шәхси эшмәкәр Лилия Тарзиминаныкы булгандыр. Шушы чарада катнашуына ихластан сөенеп, мондый мөмкинлек тудырган өчен, Васил Шәйхразыевка зур рәхмәт сүзләрен җиткерде ул. Кайчандыр бизнесвумен булырга хыялланган кыз теләген чит төбәктә тормышка ашырган. Бүген ул тәм-томнар, баллы ризыклар пешереп сату буенча үз эшен җитәкли, эш урыннары тәкъдим итә.

– Эшмәкәр буларак беренче адымнарымны Казанда ясаган идем, – диде ул. – Кияүгә чыккач, хәрби хезмәттәге ирем белән Североморск шәһәрендә яши башладык. Ике кызыбыз бар. Без анда да татар телебезгә, гореф-гадәтләргә, милли ризыкларга игътибарны киметмәдек, балаларыбызга да шуны сеңдереп яшәргә бик нык тырышабыз. Аларга дини үрнәк күрсәтәбез. Гаилә белән беррәттән, якташларыбыз белән элемтәдә торабыз, милли бәйрәмнәр оештырабыз.

Пленар утырышта Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты. Ул Россия төбәкләрендәге һәм чит илләрдәге татар эшмәкәрләрен Татарстан бизнесы белән элемтәләрне тагын да ныгытырга өндәде.

– Бүген федераль хөкүмәт ярдәмендә, гамәлдәге илкүләм проектлар, дәүләт программалары ярдәме белән Татарстан республикага федераль акча җәлеп итүдә актив катнаша. Сез дә бу программаларга кушыла аласыз. Татарстан бизнесы белән тагын да элемтәләрне ныгыту мөмкинлекләрен табыгыз. Сәүдә-сәнәгать палатасы, эшмәкәрләр, товар җитештерүчеләр берлеге, иҗтимагый оешмалар бу бурычны хәл итүгә әзер, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Аның сүзләренчә, хәзер булган темпларны киметмәү бурычы тора.

– Оялмагыз, үзегез өчен сорамыйсыз, дәүләт бурычын күздә тотып сорыйсыз, уҗәтлегегезне күрсәтегез, чөнки сез үз җирлегегездәге татар диаспорасын берләштерү бурычына да алынырга тиеш. Татар дөньясын саклап калу чараларын күрерсез дип уйлыйм, – дип мөрәҗәгать итте ул татар эшмәкәрләренә. – Без татар халкының телен, мәдәниятен, изге традицияләрен сакларга тырышабыз. Россиядә руслардан соң – икенче, Татарстанда ул – беренче милләт. Безнең өчен барлык милләтләрнең үзара тату яшәве мөһим. Фундаменталь кыйммәт бу.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Татулык хакында

«ВАЛДАЙ» КЛУБЫ ЭКСПЕРТЛАРЫ ДИН ҺӘМ БЕРДӘМЛЕК ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШАЧАК

Нигез булып торган кыйммәтләргә кайту. «Валдай» халыкара дискуссия клубының чираттагы конференциясе шул хакта сөйләшүгә багышланачак. Очрашу урыны итеп Татарстан башкаласы сайланган. Юкка түгел, билгеле. Фикер алышуга Россия һәм чит илләрнең дин әһелләре, фәлсәфәчеләр, дин белгечләре, социологлар, галимнәр чакырулы.

Оештыручылар искәрткәнчә, Казандагы очрашуның төп максаты күпмилләтле һәм күпдинле җәмгыятьләрнең тотрыклылык серенә төшенү.

– Элеккеге тарихи чор тәмамланган дәвердә, дөнья рухи һәм интеллектуаль яктан үзгәргәндә, «Валдай» клубы дәүләтләрдә эчке тәртипне билгеләүче һәм җәмәгатьчелек аңын формалаштыручы төп кыйммәтләргә – дин, мәдәният һәм сәясәт элемтәләренә мөрәҗәгать итәчәк, – ди чараны оештыручылар. Фикер алышуда белгечләр Россиянең күпмилләтле һәм күпконфессияле дәүләт төзүдәге тәҗрибәсенә дә таяначак.

Конференцияне үткәрү урыны итеп Казанны сайлаулары очраклы түгел. Татарстан башкаласы күп гасырлар дәвамында төрле диннәрнең тыгыз һәм тыныч яшәве үрнәге булып тора. Шул ук вакытта Россиядә ислам диненең мөһим үзәкләренең берсе санала. Искәртик: быел Татарстан Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны билгеләп үтә.

Конференциядә 8 илдән 20ләп белгеч катнашыр дип көтелә. Алар арасында Россия, Мисыр, Һиндстан, Иран, Малайзия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Сербия һәм Таҗикстан вәкилләре бар.

kzn.ru

100 ТОННА ЯРДӘМ

КАЗАННАН ЛИСИЧАНСК ШӘҺӘРЕНӘ ТАГЫН БИШ ЙӨК МАШИНАСЫ ЮЛ АЛДЫ

Татарстан башкаласыннан Луганск Халык Республикасындагы Лисичанск шәһәренә чираттагы 100 тонна гуманитар ярдәм озатылды.

Казанның 200ләп предприятиесе, шул исәптән фармацевтика һәм сәүдә оешмалары, мәктәпләр, идарәче компанияләр, шулай ук 600ләп битараф булмаган кеше ярдәме белән барлыгы биш йөк машинасын азык-төлек продуктлары һәм башка кирәк-яраклар белән тутыра алганнар.

Гуманитар ярдәм төялгән йөк машиналарын Казан Ратушасы яныннан озатуда шәһәр мэры Илсур Метшин да катнашты.

– Без Лисичанскида яшәүчеләр белән элемтәдә торабыз һәм, аларның ихтыяҗларыннан чыгып, беренче чиратта, иң кирәкле әйберләрне җибәрәбез, – диде ул.

Әйтик, бу юлы Лисичанск халкы үтенече белән генераторлар һәм буржуйка-мичләр сатып алып җибәргәннәр. Шулай ук җылы кием-салым, көнкүреш химиясе, тәм-томнар, төзелеш материаллары һәм башкалар тупланган. Гомумән алганда, җәмгысы 30 тонна азык-төлек һәм 70 тонна башка кирәк-ярак җибәрелгән. Аларны «Игелекле Казан» фондының складына җыйганнар.

Илсур Метшин гуманитар ярдәм җыюда катнашкан һәркемгә рәхмәтен белдерде.

– Нәкъ менә сезнең битараф булмавыгыз безгә ярдәм җыюда кыенлыклар тудырмый. Ярдәм итәргә теләк белдерүчеләр көннән-көн арта, без моңа бик шат, – диде ул.

«Игелекле Казан» фондының гуманитар ярдәм җыю пунктлары Казанның төрле районнарында урнашкан. Хәзерге вакытта шундый 18 пункт эшли. Теләге булган һәркем бу игелекле эшкә көн саен 10.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр кушыла ала.

Сүз уңаеннан, гуманитар ярдәмнең беренче партиясе Казаннан 10 ноябрьдә озатылган иде. Аны Лисичанск шәһәренә алып барып җиткергәннәр. Шәһәр администрациясе Казаннан килгән гуманитар ярдәмнең шәһәрне азат иткәннән бирле күләме буенча иң зуры булуын билгеләп үткән.

Лисичанскида яшәүчеләр, үзләренә ярдәм иткән Казан халкына рәхмәтләрен белдереп, видео яздырган. Әлеге видеоязманы Казан мэриясенең «Телеграм»дагы каналына урнаштырганнар.

– Кадерле казанлылар, Лисичанск шәһәренә күрсәткән ярдәмегез өчен зур рәхмәт! Сезнең ярдәм белән без шәһәрне торгызырга тырышабыз, – дигән видеоязмада Татарстанның Лисичанск шәһәренә ярдәм күрсәтү эше өчен җаваплы вице-премьеры Евгений Варакин.

Шул шәһәрдән бер ханым да Казан халкына видеоязма аша рәхмәтен белдергән.

– Лисичанск шәһәрендә яшәүчеләр исеменнән сезгә зур рәхмәтемне белдерәм. Безгә хәзер бик кыен, сезнең ярдәмнән башка булдыра алмыйбыз, – дигән ул.

РӘСИМ САТТАРОВ:

«БАНКИРЛЫККА ТҮГЕЛ, «БАЛКҮР»ЛЕККӘ ОМТЫЛАМ»

Шәһәрдән – авылга

Әлки районы Мулланур авылы егете Рәсим Саттаров Казанда банк хезмәткәрләре мәктәбен тәмамлаган. Белгечлек алганнан соң, үзен республиканың әйдәп баручы банкына үтә дә җаваплы эшкә чакыралар.

Рухланып-канатланып эшләп йөргән чагын хәтерлим. Авыл тормышының әчесен-төчесен татып үскән ир-егеткә банктагы эше бик ошый кебек тоелган иде. Һәрхәлдә, аена ике тапкыр уч тутырып акчасын ала. Әкренләп тагын да дәрәҗәлерәк үрләргә ирешергә мөмкинлек бар.

Шулай булды да бугай. Соңгы тапкыр күрешүемдә Рәсим инде үз-үзенә нык ышанган, аягында нык басып торучы белгеч иде. Тормышы да түгәрәкләнеп килә. Кайбыч районы Борындык авылының Ләйсән исемле кызы белән гаилә корып җибәргәннәр. Бөтен уңайлыклары булган фатирлары бар. Яңарак кына машиналы да булганнар. Иң сокландырганы: бер-бер артлы ике балалары – Сәлим белән Ясминә туган. Кыскасы, рәхәтләнеп яшәргә генә.

Бәлки шуңадыр, көннәрнең берендә аны ТНВ каналындагы «Таяну ноктасы»нда катнашучылар арасында күргәч, аптырап калдым. Баксаң, берничә ел элек Рәсим Саттаров, банктагы дәрәҗәле урынын калдырып, туган авылына кайткан, эш ачып, үзмәшгуль булып теркәлгән.

– Минем әби-бабайлар, әти-әни, туганнарым – Ходайның барлыгына, берлегенә чын күңелдән ышанган кешеләр. Әниемнең әтисе Әсәдулла бабай – авылыбызның мәзине, әти ягыннан Сәетгәрәй бабай да дин юлында була. Гомерләре хәләл хезмәттә узган. Нәселебезнең төп үзенчәлеге – умартачылык – буыннан-буынга дәвам иткән. Бала чагымнан ук күңелемә кереп калган бу изге эш мине дә гел үзенә тартып торды, – диде ул, тормышындагы кискен борылышның сәбәбен аңлатып.

Әтисе Рәфыйк Саттаров та гомере буе колхозда умартачы булып эшли. Рәсим, бала чагыннан ук аңа ияреп, урманнан кайтып кермәгән. Бәлки шуңадыр, тормышта башка юлдан китүе, банкир буларак, гөнаһлы керем исәбенә яшәве күңеленә тынгылык бирмәгәндер. Балачактан ук дин юлында булып, биш вакыт намазны калдырмаган ир-егеткә банкир булу килешми торган эш сыман тоелгандыр шул инде.

Өстәвенә, бүген дә умартачы булып эшләүче әтисе, егылып, җилкә сөяген сындыргач, авылга кайтырга сәбәп тә табыла. Умарталарның эш-мәшәкатен санап бетерерлек тә түгел бит. Кыймылдый алмый азапланып ятсаң да, бар эшне вакытында башкарырга кирәк. Андый чакта тыныч күңел белән банкта эшләп йөреп буламыни? «Менә шулай, өч ел элек банкирдан «балкүр»гә әйләнеп киттем», – дип елмая Рәсим.

Хәер, банкта эшләгән тәҗрибәсе, компьютер, интернет мөмкинлекләрен яхшы белүе монда да ярап куя. Хәзер аның эше умарта карау гына түгел. Бал җитештереп сату да әллә ни зур керем бирми, ди. Ә менә умарталар өчен төрле җиһазлар, әйтик, кәрәз рамнары, умарта мендәрләре һәрчак кирәк. Моның өчен зур производство булдыру зарур түгел. Кечкенә генә остаханә дә җитә. Шунда ук балдан ясалган төрле тәмләткечләр дә җитештереп була.

Әнисенең бертуганы Нурсинә Чувашиянең эшмәкәрлек белән дан алган Урмай авылында яши. Шул апасы белән киңәшләшеп, бал һәм умарта продукцияләреннән «Эколафта – тәмле бал» дип аталучы үз маркаларын булдырганнар. Кулланучылар аларны шул марка аша эзләп таба. Ике-өч ел эчендә егермегә якын төрдә «Эколафта», ягъни тәмле бал әйберләре җитештерәләр. Бу эштә ярдәм итүләре өчен Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, республика умартачыларының җәмәгать оешмасы, аерым алганда, оешма җитәкчесе, тәҗрибәле умартачы Шәүкәт ага Хәйруллинга рәхмәтле ул.

Әлки якларының бай табигатен, Мулланур авылыннан ерак түгел урнашкан умарталык янәшәсендәге урманның гүзәллеген сөйләп аңлату да кыен, ди Рәсим. Шул матурлыкка үзләреннән өлеш кертергә дә өлгергәннәр. Яз-көз көннәрендә әти-әнисе, хатыны һәм балалары белән бергәләп, умарталык тирәсенә төрледән-төрле җиләк-җимеш агачлары утырту гаилә традициясенә әйләнеп бара.

– Бездә үсә торган дару үләннәре, чәчәк балы һәм кәрәз калдыкларыннан ясалган файдалы катнашмаларны Казан халкы аеруча үз итә. Сәламәтлегенә игътибарлы кешеләр алдан ук заказ биреп куя. Казанда да үз кулланучыларыбыз арта. Сер түгел, төрле катнашмалар кушып сатучылар да очраштыргалый бит. Шуңа күрә халык балны инде бер сыналган умартачыдан алырга тырыша. «Элеккеге елларда балны кая куярга белми идек, хәзер җиткереп булмый», – ди үзмәшгуль Рәсим Саттаров.

Камил СӘГЪДӘТШИН

ГОМЕР ДИСБЕСЕ

Юбилей

Кеше гомере дисбе кебек. Андагы төймәләр – узылган еллар. Еллар дисбегә төймәләр өсти. Кайчак туктап каласың да күңел белән янәдән дисбедәге төймәләр өстеннән үтәсең, артта калган елларны янәдән барлыйсың. Профессор, педагогика фәннәре докторы, Россиянең мактаулы транспорт хезмәткәре, Россиянең беренче дәрәҗә «Почетлы юлчы»сы, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Мари Иленең, Удмуртиянең, Татарстанның атказанган төзүчесе Мөхәммәт ГАТИЯТУЛЛИН шушы көннәрдә үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Ул – искитмәле матур хезмәт юлы үткән кеше. Беренче эш урыны – туган авылының мәктәбе (әле дә булса аның укытучылары, безне Мөхәммәт абый укытты, дип горурланалар), аннан Балтач районы юллар идарәсен җитәкли. Үзгәрешләргә бик бай, авыр елларда Кукмара районында район башлыгы булып эшли. Идел-Нократ федераль юллар идарәсен оештыруда катнашып, ун ел аның җитәкчесе була. Бүген Казан төзелеш һәм архитектура академиясендә белем бирә. Иң мөһиме: кайда гына эшләмәсен, һәрчак үзеннән соң матур эшләр калдыра алган. Дисбедәге мәрҗәннәрнең һәркайсы матур хатирәләр, зур эшләр белән кыйммәтле. Юбилей уңаеннан Мөхәммәт Гатиятуллинның әнә шул дисбедәге мәрҗәннәрен барладык.

:: Мөхәммәт Хәбибуллович, кичә һәм бүген дисәк, нәрсәләр тамырдан үзгәрде?

– Без – совет чоры тәрбиясе алган буын. Ул чордагы тәрбия, мөнәсәбәт, яшәү рәвеше бүгенгедән бик күпкә аерыла. Шул чордан чыгып, безгә базар мөнәсәбәтләренә килеп керергә туры килде. Әлбәттә инде, күп нәрсәгә ялгышлар аша килдек, чамалап эшләп өйрәндек. Кешеләрдә бүген эчкерсезлек кимеде, җаваплылыкны тою зур түгел.

Кеше – иң зур байлык. Һәр җирнең, илнең байлыгы – кеше. Кешеләргә мөнәсәбәт, бер-береңә мөнәсәбәт яшәешнең дәрәҗәсен билгели. Яхшы якка үзгәрешләрне дә күрә белергә кирәк. Хезмәт юлымның күп өлеше юл эшенә бәйле буларак әйтәм: моннан 20 ел элекке белән чагыштырганда алга китеш бик зур. Юлларның торышы, техник база, төзү материаллары белән тәэмин ителеш – җир белән күк арасы. Бүген юлларның торышы бик яхшы. Юл ул һава кебек: яхшы юлдан барганда берни сизмисең, сикәлтәгә керсәң генә, юлның начарлыгы сизелә.

:: Бик матур, үзенчәлекле хезмәт юлында иң истә калган еллар кайсы? Сез – иң беренче чиратта укытучымы, әллә төзүчеме?

– Иң сагынып искә алган елларым – институтны тәмамлап, Балтач юллар идарәсендә эшләгән еллар. Кичәге студент – бүген җитәкче. Анда мин үземчә рәхәтләнеп, кинәнеп эшләдем. Бөтен алган белемемне тормышта кулландым, карарлар кабул иттем, тәҗрибә тупладым. Минем күңелемдә мөгаллим һәм төзүче яши. Алар бик дус. Юл хезмәтендә алган бөтен тәҗрибәне яшьләргә тапшырасым килә.

:: Җитәкче кеше өчен иң кирәкле сыйфатлар нинди дип санийсыз?

– Иң беренче чиратта кешене үзең хөрмәт ит, ышан, үзең дә алдама. Булдыра алсаң, эшләп күрсәт, эшли алмыйсың икән, ни өчен эшләп булмаганны аңлат. Ялган вәгъдәләр бирмә. Һәр кеше белән аралашып, аңлашып эшләп, әллә нинди зур проблемаларны хәл итеп була. Тигез урында түмгәк ясарга кирәкми.

:: Сез – туган авыл, дип янып яшәүче кеше. Авылларны ничек саклап калып була?

– Авылларны саклап калырга соңдыр инде ул. Инвесторлар керү аның үзәгенә чапты. Үз вакытында халыкка күп итеп терлек биреп, колхозлар азык җитештереп бирсә, халык үзе җитештергән продукцияне сата алса, җирдән, терлек асраудан аерылмаган булырлар иде. Җир кешесе һәр нәрсәгә бик сизгер. Аңа бары тик мөмкинлек бирергә кирәк. Бүген авылда тотрыклы хезмәт хакы юк. Язын, көзен алган хезмәт хакы белән генә 12 ай яшәп булмый. Авыл хуҗалыгында җитештерелгән продукция бәясенең түбән булуы да тискәре йогынты ясый. Авылдан киткән кешенең, йөзгә дип әйтмим, меңгә бере генә кайта. Шәһәр авылларны йотып бара. Әлбәттә, барлык авыллар да бетмәс, ләкин авыллар хәзер башка инде.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хөрмәтле Мөхәммәт Хәбибуллович!

Кукмара муниципаль районы Советы, районыбыз халкы, җитәкчеләр һәм шәхсән үз исемемнән Сезгә булган тирән ихтирамыбызны җиткереп, Сезне тормышыгыздагы истәлекле вакыйга – 70 яшьлек күркәм юбилеегыз белән котлыйбыз!

Сез бу тантаналы көнегезне тормыш тәҗрибәсе, зирәклек туплаган, яшәү мәгънәсен тирәнтен аңлаган, районыбызның, республикабызның социаль-икътисади үсешенә лаеклы өлеш керткән абруйлы оста җитәкче, югары дәрәҗәле фән эшлеклесе буларак каршылыйсыз.

Кукмара районының Сез җитәкләгән 1990–1999 еллары – ил өчен көтелмәгән кискен борылышлар, зур үзгәрешләр, озак вакытлар дәвамында тупланган рухи һәм матди кыйммәтләрнең югалуына дучар ителгән елларга туры килде. Ләкин бу зур сынауны сынмыйча уздырып җибәреп, районны бербөтен итеп саклауга үз өлешегезне керттегез. Озакка сузылган төрле өлкәләрдәге реформалар, кризисларга карамастан, сәнәгатьтә төп товар җитештерүчеләр – итекче, тегүче, мехчы, авыл хуҗалыгы тармагы сакланып калды. Финанс кытлыгы булуга карамастан, һәр ел саен күпләп социаль объектлар, торак йортлар, юллар, капиталь күперләр төзелде, газлаштыру кызу темплар белән барды. Алга таба хезмәт юлыгызда югары дәрәҗәләргә ирешү, республика һәм федераль оешмаларда җитәкче вазыйфаларын җиренә җиткереп башкару – Сезнең һәр тапшырылган эшкә үтә җаваплы каравыгыз, максатчанлыгыгыз һәм профессиональлегегезнең күркәм нәтиҗәсе.

Хөрмәтле Мөхәммәт Хәбибуллович, районыбызга булган зур игътибарыгыз, кайгыртучанлыгыгыз өчен ихлас рәхмәтебезне белдерәбез. Сезгә һәм якыннарыгызга саулык-сәламәтлек, озын гомер, гаилә иминлеге, һәр өлкәдә мул уңыш белән үрелеп баручы яңа хезмәт җиңүләре теләп, зур хөрмәт һәм ихтирам белән,

Кукмара муниципаль районы башлыгы Сергей Димитриев

Мөхәммәт Хәбибуллович ун ел Идел-Нократ федераль юллар идарәсен җитәкләде. Идарәгә ул елларда Татарстан, Мари Иле, Удмуртия Республикаларының, Киров өлкәсенең федераль юллары карый иде. 41 федераль юл идарәсе арасында Идел-Нократ зурлыгы буенча – бишенче урында.

Нәкъ менә шушы елларда безнең юллар аның белән кисеште. Ул –идарәнең беренче җитәкчесе, аны оештырып, билгеле бер эзлеклелеккә салып, коллективны җыйнап эшләтеп җибәрүче.

Иң беренче чиратта мин аның оста оештыручы булуын әйтеп үтәр идем. Эшнең нәтиҗәсен алдан күреп, планлы рәвештә шул максатка бару, дөрес итеп бурычларны куя белү – аның иң асыл сыйфатларының берсе. Ул – зыялы, тирән белемле, кызыксынучан шәхес. Үзенең кул астына да яхшы белгечләрне туплый алды. Әлеге сыйфатлары һәрчак югары нәтиҗәгә ирешергә, аңлашып эшләргә мөмкинлек бирде.

Мөхәммәт Хәбибуллович бүген дә хезмәттә: үзенең барлык белемен, тәҗрибәсен студентлар белән бүлешә. Димәк, аның эше дәвамлы. Мин аңа һәркем өчен иң мөһим булган сәламәтлек телим. Үзе салган юллардан горурлык хисен тоеп йөрергә язсын.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты,
«Алексеевскюлтөзү» ААҖ Директорлар советы рәисе Фоат Вәлиев

Мөхәммәт Хәбибуллович – бик позитив мөгаллим! Орышканда да артык усалланмый гына, кешене рәнҗетми, кимсетми генә шелтәли иде. Беркайчан да бер студентны да батырмый, ничек кенә булса да аңлатырга, ялкау студентның укуга карата мөнәсәбәтен яхшы якка үзгәртергә тырыша.

Ул – көчле практик. Теорияне укытканда һәрвакыт практикага таянды. Ул –үз эшенең остасы, эшен яратып, җиренә җиткереп башкаручы, чын мәгънәсендә мөгаллим. Ул безне җаваплылыкка, эшкә карата яхшы мөнәсәбәткә, гаделлеккә өйрәтте. Аның студенты булу – үзенә күрә бер бәхет, дәрәҗә.

Мөхәммәт Хәбибуллович, сез супер! Гел шундый булып калыгыз, студентларыгыз картаерга ирек бирмәсен.

Иң яхшы теләкләр белән, КГАСУ студентлары исеменнән
Алмаз Һадиев, Диас Әхмәтҗанов, Инсаф Ибраһимов,
Раил Әхмәтханов, Айдар Гатиятуллин, Инсаф Насыйбуллин

Саный китсәң, туган авылыбыз Арбор өчен **Мөхәммәт Хәбибуллович**ның башкарган эшләре бихисап. Бик күпләргә үрнәк булып, иң беренчеләрдән үзенең туган авылына ярдәм итә башлаган кешеләрнең берсе ул. «Сезнең Мөхәммәтегез бар» дигән сүзләрне арборлылар күп ишетә һәм моның белән горурланалар. Клуб, мәчет төзелеше, плотина, асфальт юллар… Берсе дә аның ярдәменнән, киңәшеннән башка эшләнмәде. Дәүләт программасын юллап алу өчен дә ярдәм итүче, башлап йөрүче кирәк. Без авылда эшлибез, җир кешеләре, бөтен нәрсәне белеп тә бетерә алмыйбыз. Мөхәммәт Хәбибуллович исә һәрнәрсәдән хәбәрдәр, барысын юллый, сөйләшә, таба. Ул – үз сүзендә тора торган җаваплы, тирән белемле кеше. Әлеге сыйфатлары аны белгән һәркемдә хөрмәт уята. Шуңа күрә аның сүзе дә һәркайда үтә. Барлык арборлылар исеменнән, Мөхәммәт Хәбибуллович, Сезгә зур рәхмәтебезне белдерәбез! Исән-сау булып, бик күп язларны, ап-ак кышларны каршыларга язсын. Туган җиргә, авылдашларга кылган игелекле эшләрегез куаныч, Аллаһның рәхмәте булып үзегезгә әйләнеп кайтсын.

Барлык арборлылар исеменнән
«Арбор» җәмгыяте җитәкчесе Хәмит Баязитов

Һәр җирлек үзенең булдыклы егет-кызлары белән бәяләнә, данлана. **Мөхәммәт Хәбибуллович** – кайда гына эшләсә дә, үзенең хезмәте белән хөрмәткә лаек булган кеше. Аның хезмәте дәүләт тарафыннан бихисап бүләкләр белән бәяләнсә, халык арасында кешеләргә булган мөнәсәбәте белән абруй казанган шәхес. Безгә, аның якташларына, туган җирне ярату, зурлау үрнәге дә ул. Мөхәммәт Хәбибуловичны 70 яшьлек юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз. Сау-сәламәт булып яшәргә, эшләргә язсын. Гаилә иминлеге, җан тынычлыгы телибез.

Балтач якташлар җәмгыяте

АЛЁША-АЯЗ:

«ДИННЕ АЛЫШТЫРГАЧ, ҮЗГӘРЕШЛӘР БАШЛАНДЫ»



Яңа Чишмә районының Зирекле авылына баргач, юлыбыз мәдәният йортына төште. Анда безне, елмаеп, Алексей исемле яшь кенә егет каршы алды. Аралаша-сөйләшә торгач, егетебезнең бик тә үзенчәлекле сыйфатлары, күркәм гадәтләре барлыгы ачыкланды.

Заманында Алексей Тушнинскийның бабалары күршедәге Красновидово авылында яшәгән булган икән. Ул авыл таркалгач, гаиләләре Зириклегә күченгән. Татар авылында гомер итү балаларның телендә, көнкүрешендә генә түгел, диннәрендә дә чагылыш тапкан: алты ел элек Алексей динен алыштырган.

– Рус милләтеннән булсам да, ислам дине һәрвакыт минем янәшәдә булды, – дип аңлата егет әлеге карарын. – Татар авылында туып-үскәч, кечкенәдән үк мәчеткә йөрдем. Моннан тыш, мәктәптә Ильяс хәзрәт Сөләйманов дин сабаклары бирә иде. Соңыннан мәчет каршындагы мәдрәсәдә белем алдым. Рамазан айларында хәзрәткә ифтарлар әзерләшергә, башка дини мәҗлесләрдә ярдәм итә идем. Шуңа күрә 9 нчы сыйныфны тәмамлаганнан соң, ислам динен кабул итәргә кирәк дигән карарга килдем. Минем, ниһаять, бер Аллаһка мөрәҗәгать итәсем килде.

Ислам динен кабул иткәч, Алексей Аяз исемен алган. Шулай итеп, ифтар мәҗлесе вакытында егет чын мөселман булган. Гаиләсе Аязның бу җитди карарын аңлап кабул иткән. Хәер, 1,5 ел элек алдан бертуган абыйсы да ислам диненә күчкән булган.

– Без – ишле гаилә. Дүрт туганым бар. Абыем да исем-фамилиясен тулысынча үзгәртеп, аларны документта рәсмиләштерде. Дмитрий Тушнинский иде. Хәзер Динар Сафин булып йөри. Әнием аны да, мине дә аңлады, каршы килмәде. Үзе православие динендә булса да, исламны бик хөрмәт итә. Йортта ике дин бәйрәмнәрен дә уздырабыз. Башка туганнарым да безгә хөрмәт белән карый, – ди ул.

Бер милләт һәм ике дин вәкиле яшәгән йортта үзара аралашулар күбрәк татар телендә икән.

– Әнием дә, туганнарым да татарча аңлый, сөйләшә. Хәтта бабам да күпчелек татар сүзләрен аңлый. Тик аның янында барыбер күбрәк русча сөйләшәбез, – ди Аяз.

Аяз исемен алыштырса да, документта аны рәсми рәвештә теркәмәгән. Шуңа күрә ул тормышта ике исем белән йөри. Яңа танышлыклар булдырганда, егет үзен Аяз дип таныштырса, документ күрсәтергә кирәк булганда, Алексейга әйләнә.

– Киләчәктә документларымны да алыштырырмын, дип уйлыйм. Тик әлегә моның өчен шактый вакыт һәм акча кирәк. Ләкин алыштырмыйча да булмый, чөнки ике исем белән йөрү тормышымда нык чагылыш таба, – ди ул. – Ислам динен кабул иткәннән соң, тормышымдагы, гаиләдәге һәм эштәге үзгәрешләр бик нык сизелә. Тик алар гел уңай гына түгел, чөнки миңа ике исем белән яшәүнең авыр буласын алдан ук әйткәннәр иде. Еш кына икеләнәм, сайлау алдында калам. Мәсәлән, уку белән ни эшлисен әле дә хәл итмәдем. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, КФУның Чаллыдагы филиалында дизайн сәнгате факультетында укыган идем. Тик аны тәмамламадым, авылга кире кайттым. Хәзер аны тәмамларгамы-юкмы дип уйланам.

Әлеге көндә Алеша-Аяз авыл мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе булып эшли. Авыл балаларына түгәрәкләр оештырып, аларны сәнгатькә тарта.

– Авылдашлар арасында мине ислам диненә хәзрәтнең басымы аркасында килде, дип уйлаучылар да бар. Юк, һич кенә дә алай түгел. Бу бары тик үземнең генә карарым иде. Мәчеткә яратып йөрим, кирәк булса, хәзрәткә дә ярдәм итәм. Акрынлап догалар да ятлый башлаячакмын, – ди йөзеннән елмаю китмәгән ачык күңелле Алеша-Аяз.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Ярамый!

Бозга ышанма!

Көннәр салкынайтса да, елгаларда боз катмаган әле. Шунлыктан сулыкларга керергә ярамый. Бозга ышанма, дип күпме генә кисәтсәләр дә, инде батып үлүче бар.

Шушы көннәрдә Казанның Борисоглебск бистәсендә яшәүче 53 яшьлек ир-ат суга баткан. Чөнки боз кешеләрне күтәрә алырлык дәрәҗәдә катмаган әле. Бу хакта «Татар-информ»да узган очрашуда Татарстанның Кече көймәләр буенча баш дәүләт инспекторы Юрий Венедиктов сөйләде.

– Күп кенә сулыклар ачык әле. Нократ, Чулман елгаларында боз катмаган. Лаеш районының Ташкирмән авылы янында Чулман елгасында да бозга ышанып булмый. Балык тотар өчен боз катламы 7 сантиметр булырга тиеш. Без инде балыкчыларга сабыр итәргә кушабыз, катлам 10 сантиметрга җиткәч керү ышанычлырак дибез, – ди ул. – Ел башыннан республика сулыкларында 108 кеше батты. Шуларның 81ен коткарып булмады. Кешеләр гомерләре хакында уйланса иде.

Коткаручылар халыкка сак булырга куша. Бу балыкчыларга гына түгел, боз өстенә тимераякта шуарга чыгучыларга да кагыла. Елгада шуар өчен боз катламы 12 сантиметрга җитәргә тиеш. Юрий Венедиктов, әлегә республикабызда салкыннар күзәтелми, ди. Елгаларда боз катсын өчен 15 градуслы салкыннар кирәк.

– Балыкчылар гына сабыр итми. Төрле фотолар җибәреп, монда балык чиртә, дип, бер-берләрен чакырып китерәләр. Ышанып, юка бозга керүчеләр дә бар. Берәү дә коткару жилеты кияргә ашыкмый, – ди ул. – Әгәр берничә балыкчы бергә утыра икән, бу да бозның ярылып китүенә бер сәбәп булып тора. Балыкчы белән балыкчы арасы кимендә 3 метр булырга тиеш. Кабатлап әйтәм: әлегә бозга керергә ярамый.

Бозның калын түгеллеген балыкчылар үзләре дә белә. Түбән Камада яшәүче Назыйм Галиәхмәтов та шушы көннәрдә балык тотып кайткан. Ул яшерми: бозга керерлек түгел әле. Шуңа күрә яр буенда гына балык тоткан.

Һәркем үз гомерен үзе сакларга тиеш. Юрий Венедиктов та шулай ди. Ул әти-әниләргә дә балаларын бозга кертмәскә киңәш итте.

– Үзләрен генә чыгарып җибәрмәгез. Контрольдә тотыгыз, – ди ул. – Быел республикада 10 коткару посты эшләячәк. Балыкчылар күпләп җыела торган 107 урын барлыгы билгеле. Анда 10 меңнән артык кеше балык тота. Безне коткарырлар әле, дип кенә утырып булмый. Күңелсез хәлләр килеп чыкмасын өчен, алдан хәстәрен күрегез. Яныгызда телефон булсын, бозның калынлыгын таяк белән тикшерегез, иптәшегез суга төшсә, тиз арада ярдәм итү ягын карагыз.

Коткаручылар һәрдаим елга буйларына рейдка чыга икән. Бозга керүчеләрне дә, машиналарын дөрес җиргә куймаучыларны да, кар чаналарында йөрүчеләрне дә штрафка тарталар. Барысы да аларның гомерен саклау өчен эшләнә. Балыкчылар гына гомернең балыктан кыйммәт икәнен аңлап җиткерми. Әнә Назыйм абый да: «Без анда ял итәбез, хатын борчымый, балыкның теле юк бит», – дип шаярта.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Дубликат диплома об окончании КГМУ по специальности стоматология БВС №0552785, регистрационный № 689 от 27.03.2003 года, выданный на имя Хайриевой Зульфии Гильмиевны считать недействительным в связи с утерей.

Спорт кына түгел бу

ГТО: гәүдә төзлегенә омтылыгыз!

Шагыйрь әйтмешли, ГТО ул – үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер кеше аны яңарта. Өлкәннәргә дә, хәзерге яшьләргә дә таныш булган өч хәрефле бу сүзнең әһәмияте турында Татарстанның спорт министры урынбасары Илдар САДРИЕВ белән сөйләштек. Саннар гына әйтеп калмады, киңәшләр дә бирде ул.

tatarstan.ru

:: Бүген әлеге системаның яңалыгы нидән гыйбарәт?

– Бүгенге шартларда ГТОның әһәмияте тагын да артты. Тәрҗемә итсәк, хезмәткә һәм оборонага әзерлек дигәнне аңлата. Әлеге система кешенең физик әзерлеген ачыклауны максат итеп куя. ГТОның илкүләм комплексында Татарстаннан 860 меңгә якын кеше теркәлде. Шулардан 553 меңнән артыгы ГТО сынавын тапшыруда катнашты.

:: Аларның күбесе укучылар һәм студентлар икәнне чамалау кыен түгел...

– Республика шәһәр һәм районнарында тест уздыру буенча 55 үзәк эшли, 385 тест узу урыны бар. Аларны спорт җиһазлары белән тәэмин итү эше бара. «Динамо» физик культура һәм спорт җәмгыяте тәкъдиме белән Казандагы «Динамо» үзәгендә яңа тест узу үзәге ачылды. Казанда хәтта ГТО балалар бакчасы да бар.

Чыннан да, сынау узучыларның күбесе – мәктәп укучылары, студентлар һәм өлкән яшьтәгеләр. Хәзер урта яшьләрдәге, эшли торган кешеләрне җәлеп итү эше алып барыла. Үрнәк күрсәтүчеләр дә бар. Дәүләт оешмалары арасында Татарстан Президенты Аппараты, Министрлар Кабинеты, кайбер министрлыкларның хезмәткәрләре актив. Районнар арасында Азнакай, Саба, Балтач алда. Анда район башлыклары, башка җитәкчеләр үзләре үрнәк күрсәтә. Азнакайда, әйтик, мобиль бригадалар авылларга йөри һәм тест уздыра. Башта кызыксындырырга, аннары шартлар булдырырга кирәк.

:: Ә халыкның мөнәсәбәте ничек? ГТОны мәҗбүри эш итеп кабул итүчеләр дә бар.

– Беркемне дә мәҗбүр итүче юк. «ГТО нәрсә бирә?» – дип сорыйлар. Хәлеңне белү генә түгел, сәламәтлегеңне тикшерү дә ул. Шуңа күрә сынауга әзерлексез барып керергә киңәш итмәс идем. Чөнки гади генә нормативлар түгел. Әзерләнергә һәм шөгыльләнергә кирәк.

Билгеле булганча, ГТО сынавын узучыларга вузга укырга кергәндә баллар өстәлә. Күпме икәнен һәр уку йорты үзе хәл итә. Әмма кайчак бер баллның да әһәмияте зур булырга мөмкин. Зуррак стипендия алу мөмкинлеге дә бар. Оешма-предприятиеләр ял көне яки премия белән сөендерергә мөмкин. Иң мөһиме – кеше сәламәт икән, ул эшен калдырмаячак, нәтиҗәсе яхшырак булачак, димәк, күбрәк файда китерәчәк. Предприятиеләрнең эшче һәм хезмәткәрләрен кызыксындыру буенча төрле ният һәм тәкъдимнәре бар. Әмма иң элек кеше үзе кызыксынырга тиеш.

:: Ә шартлар?

– Үзгәрә. Беренче елларда барысы да моны гади генә сынау дип уйлый иде. Аннары таләпләре генә түгел, мөнәсәбәт белән сыйфат та үзгәрде. Сынау узарга теләк белдерүчеләр күп, әмма яшермим, без теләгән дәрәҗәдә үк түгел. Ә кызыксыну бар. Без үзебез дә аларга ярдәм итәргә тырышабыз. Әйтик, «Тимерман», «Казан марафоны» кебек кеше күп катнаша торган ярышларга ГТО сынауларында да исәпкә алырга мөмкин булган дистанцияләр кертелә. Шуннан кызыксынып китеп, ГТО үтәргә баручылар бар. Җыеп әйткәндә, бу эш халыкны спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен дә башкарыла.

ГТО буенча төбәк операторы халыкны кызыксындыру өчен төрле чаралар, бәйгеләр уздыра. Җәйге һәм кышкы фестивальләр оештыралар, ГТО уеннары, Гаилә фестивале узды. Система эшли. Теләгән һәркем, сынау узып, үзенә яңа максатлар куя ала.

:: Таләпләре авыр булып, кешенең күңелен кайтармыймы?

– Төрле кеше була. Кемдер, булдыра алмаса, киресенчә, үҗәтләнә башлый бит. Көмеш һәм бронза белән генә канәгатьләнмичә, алтын өчен тырышучылар бар. Әйтик, элеккеге яшь категориясендә алтын билге алган идем. Хәзергесендә исә нәтиҗәләр – алтын белән көмеш арасында. Димәк, омтылыш өчен сәбәп бар.

:: Сезнең эштә спорт белән даими шөгыльләнмичә булмый. Ә менә физик культурадан ерак булганнар нормативларны үти аламы?

– Даими шөгыльләнми икән, авыр булачак. Мин волейбол уйныйм. Хәтта кайбер спортчыларга да авыр була. Кемдер көчле, әмма аңа йөгерү кыен булырга мөмкин. Әйтәм бит, бардың да тапшырдың түгел. Норматив тапшыру өчен табиб белешмәсе дә кирәк. Димәк, спорт белән даими рәвештә шөгыльләнмичә булмый. Моның өчен шартлар бар. Нәтиҗәсе – сәламәтлек һәрберебезгә кирәк.

Татарстанда **553804** кеше ГТО сынавында катнашкан, **283239**ы аны уңышлы тапшырган.
«Алтын» билге алучылар – **77436.**
«Көмеш» билге алучылар – **101755.**
«Бронза» билге алучылар – **104048.**

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 ЯЗЫЛ! 2023 елның беренче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына язып

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 БҮЛӘККӘ
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

П2435 җомга саны
512 сум 70 тиен

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга
1143 сум 96 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+ реклама

КАМЧЫСЫЗ ДА БУЛМЫЙ

Лилиана Вәлитова

Чыбыкны яшьтән бөгәргә кирәк. Лаеш районы Кече Елга авылында яшәүче Маһирә апа Шәвәлиева бала тәрбияләүнең иң төп кагыйдәсе дип әнә шуны атый. Бигрәк тә ир бала үстерүчеләр колагына әйтелгән сүзләр бу. Җиде малай тәрбияләгән Маһирә апа белми әйтмәс! Лачындай егетләр үстереп кенә калмыйча, аларны чит җиргә таратмыйча саклап та кала алган ул. Җиде улы да авылда төпләнеп яши. Киленнәре дә – шушы Кече Елга авылыннан.

Шәвәлиевләрнең иң өлкәне – Нургали абый белән Маһирә апа яшәгән йортка таба атлыйбыз. Тугызынчы дистәсен ваклаучы ак әби бүген болын кадәр иркен, төзек йортта төпчек улы белән яшәп ята. «Авылда калмау турында уйлап та карамадык. Менә бу өйне энекәшләр белән бергә салдык. Аннары һәркайсыбызга йорт күтәрдек. Бөтен эшне бергә-бергә, үзебез башкарып чыктык. Читтән кеше яллап эшләтү уе башыбызга да килмәде», – ди Нургали абый.

Гаҗәп бит! Тырышлыкларына гына түгел, бердәмлекләренә дә сокланырлык! Нургали абый үзе моны әти-әни тәрбиясе җимеше дип атый. «Әнидән күбрәк курка идек. Сүз белән әйтеп тормый, күз карашы белән генә тыңлата иде ул безне. Кечкенәдән эшләп үстек. Безнең гаиләдә эшне ирне-кенә-хатынныкына бүлеп тору дигән нәрсә булмады. Көнлек эш бүленгән иде: кемдер ашарга пешерә, кемдер мал карый, кемдер өй җыештыра. Кечерәк балаларны карау да безнең өстә булды», – дип искә ала Нургали абый.

Бүген авылда механизатор булып эшли ул. Бертуган Шәвәлиевләрнең җидесе дә, әтиләре эшен дәвам иттереп, шушы һөнәрне сайлаган. Колхозлар таралып, дөньялар үзгәргәч кенә, күбесенә башка юлдан китәргә туры килгән.

Нургали абыйны тыңлагач, җиде ул үстергән батыр ананы күрәсе килү теләге тагын да көчәйде. Без килеп кергәндә, Маһирә апаның төшке аш әзерләп йөргән чагы иде. Әллә кайдан елмаеп каршы алды ул. Тугызынчы дистәсен ваклый димәссең дә! Бер эш белән мәш килгәндә, берочтан әллә ничә эш башкарырга өлгерә. Тик утырып тора торганнардан түгел. Шушы яшендә бакча тутырып яшелчә, җиләк-җимеш үстерүен, аннары шулардан кышка кайнатма, консервланган ризыклар әзерләвен белгәч, бөтенләй гаҗәпкә калдым.

– Малайларны да шушы эш белән җиндем инде мин, – дип елмая үзе. – Котырып уйный башласалар, эш куша идем. Әтиләре колхоз эшеннән кайтып керә алмагач, аларны тәрбияләү минем өстә булды. Бик кырыс идем. Сорамыйча урманга китсәләр, артларыннан барып, җилтерәтеп алып кайтам. Бездә әти-әнигә каршы сүз әйтү дигән нәрсә юк иде. Берне генә «ямадым». Шулай итмәсәң, җиде малай үстереп булмый. Кызларны да җиңеп булмый әле. Чыбыкны яшьтән бөгәргә кирәк, – ди Маһирә апа.

Нургали абый бу урында балачактан бер очракны искә алды. Язгы ташу вакытында аздан гына исән калган икән ул. «Безнең артта гына инеш бар. Ташу вакытында ярларыннан ташып чыга ул. Әни: «Суга якын бармагыз», – дип, гел кисәтеп торса да, барыбер бардым шунда. Ничек агып китүемне аңышмыйча да калдым. Иии, әнидән эләкте инде кайткач! Резин итек өзелеп чыкканчы кыйнады. Әле дә бүгенгедәй күз алдында тора шул вакыйга», – ди Нургали абый.

Андый чакта кырыс булуның артыгы юк, билгеле. Балачакта салынган тәрбия гомер буе озата бара бит. Дөресен генә әйткәндә, Маһирә апаның уллары әле бүген дә әниләреннән бераз шүрләп тора. Инде үзләре дә ир уртасы булган малайларның күз карашыннан ук аңлашыла бу. Әни кешегә чиксез хөрмәт һәм рәхмәт катыш шүрләү ул. Маһирә апа моны үзе дә яшерми.

– Улларым әле дә миннән куркып торалар. Төп булышчыларым булдылар. Сыер да савыштылар, идәннәр дә юыштылар. Киленнәремнән дә уңдым, Аллаһка шөкер. Гел килеп, хәл белешеп, ярдәм итеп торалар. Балаларымның тормышларына карап сөенәм, шөкер итәм. Әтинең: «Балаларыгызны теләсә кая таратмагыз, читкә чыгарып йөртмәгез», – дигән сүзе бар иде. Мин аларны җибәрмәс тә идем. Үзләре дә китәргә теләмәде, – ди Маһирә апа.

Шул рәвешле бертуган Шәвәлиевләр – туган нигезне генә түгел, туган авылны да саклаучылар. «Тырышкан кеше авылда да менә дигән итеп яши ала. Зарланган кешегә зар өчен сәбәп җитәрлек», – ди алар үзләре дә. Тырышлар рәтенә керүләре белән бәхетле алар.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

УТЛЫ СИХӘТ

КУРКЫНЫЧ ТОЕЛГАН КҮРЕНЕШ КЕШЕНЕ ДӘВАЛЫЙ ДА АЛА

Шөгыль

Ут белән массаж ясау турында ишеткәнегез бармы икән? Азия илләрендә бигрәк тә популяр ул. Хәзер инде Россиядә дә тарала башлаган. Утлы массажны башкача «императорлар массажы» дип тә атыйлар. Кызыксынуны алга сөреп, аның үзенчәлекләре, организмга файдасы һәм зыяны турында әлеге төр массажны ясаучы Елена ДРОЖДЕВАдан сорадык.

– Озак вакыт җитәкче булып бер компаниядә эшләдем. Эш графигым шактый тыгыз иде. Әлбәттә, ару-талу да булды. Мондый эшнең минеке түгел икәнен аңлый идем. Тормышта үз урынымны табасы килә бит. Акча өчен генә түгел, күңел канәгатьлеге өчен дә эшләү, кешеләргә файдалы буласы килү теләге зур иде. Кешеләрне сихәтләндерәсе, рәхмәт ишетәсе килде, – дип сөйли бу шөгыленә алыну тарихын Елена. – Берничә ел Таиландта яшәп алдым, шул вакытта утлы массажга өйрәндем. Махсус укулар үттем. Иң элек бу төр массажны якыннарыма, дусларга ясап карадым. Алардан бик күп рәхмәт сүзләре ишеттем. Алар күзгә күренерлек үзгәрде, тормышка кире кайттылар, дисәм дә була. Шуннан соң массажны башкаларга да ясый башладым. Хәзер инде үзем дә өйрәтәм. Укучыларым Казан һәм Татарстан белән генә чикләнми. Хәтта Россиянең башка шәһәрләреннән махсус минем янга килеп тә, онлайн рәвештә дә укыйлар. Чит илләрдән дә мөрәҗәгать итүчеләр бар.

:: «Ут» сүзе үзе үк шүрләтә. Утлы массаж дигәне тагын да куркынычрак... Бу массажны ничек ясыйлар соң? Кешене тереләй утка ташлау түгелдер бит инде бу, Елена?

– Әйтүемчә, утлы массаж – Кытай традицион медицинасының үзенчәлекле бер ысулы. Аны бары тик дәүләт белән идарә итүче династия вәкилләренә генә ясаганнар. Аның әле киң кулланышка кереп китүенә дә күп вакыт үтмәде. Утлы массажны организмны сихәтләндерү, хәл алу, ябыгу, терәк-хәрәкәт аппараты авыруларын дәвалау өчен кулланалар. Кытай медицинасында утның чирләрнең төп сәбәбенә йогынты ясавына ышаналар. Ут энергиянең организм буенча циркуляциясенә булыша, торгынлыкны юк итә.

Утлы массаж – куркыныч процедура түгел. Тәндә ут эзләре дә калмаячак, пешү дә булмаячак. Башта кешенең тәнен, эфир майлары ярдәмендә, массаж хәрәкәтләрен кулланып, йомшартабыз. Аннан тәнне җәймә һәм ике юеш сөлге белән каплыйбыз. Сөлгеләргә массажчы спирт сала. Аның да үз схемасы бар. Шул сөлгеләргә ут төртәбез һәм тагын бер юеш сөлге белән каплыйбыз. Шул рәвешле, ут сүнә, ә аның җылысы тәнгә тарала. Шунысын да әйтергә кирәк: ялкын җылысы сөякләргә кадәр үтеп керә ала. Шулай итеп берничә тапкыр кабатлыйбыз. Тәнгә бик рәхәт җылы йөгерә. Мондый төр массаждан соң, гадәттә, кешегә өйдә калып, озак итеп йокларга киңәш ителә. Мин массаж ясаганда җырлый торган касәләр дә кулланам әле. Алар кешене процедурага әзерләргә, тынычланырга булыша.

Шунысын да әйтә алам: төрле кешедә ут төрлечә яна. Исе, төсе белән дә аерыла. Бу кешенең тәнендәге энергиягә бәйле. Ул безнең организмның ягулыгы бит инде. Энергия аз икән, ут янмый дисәң дә була.

Хәзер менталь, рухи сәламәтлек турында да күп сөйлибез. Утлы массаж бу җәһәттән дә файдалы. Тискәре энергияне юк итә, ауланы чистарта. Массаждан соң кеше тынычлана, начар уйларыннан арына.

:: Утлы массаж кемнәргә аеруча файдалы, ә кемнәр бу процедурадан читтәрәк торырга тиеш?

– Күрем көннәрендә, йөкле хатын-кызларга утлы массаж тыела. Шулай ук йөрәк авырулары, югары кан басымыннан интегүчеләргә дә андый массаж ярамый. Онкология, шикәр диабеты, тире авырулары (экзема, псориаз), салкын тию билгеләре булган кешеләргә дә утлы массаж ясамыйбыз. Хәмер белән дус булучыларга да тыела бу.

Массаж кемнәргә ярый соң? Остеохондроз, ревматизм, варикозның башлангыч стадиясен кичерүчеләргә ясарга ярый. Буын авыртуларыннан интегүчеләргә дә мөмкин. Утлы массаж баш авыртуларын киметә, ярсуны баса, нерв системасын тынычландыра. Гомумән, бу массаждан соң эчке органнарның эшчәнлеге яхшыра. Кәефне күтәрү, хәлне яхшырту өчен генә дә массажга килергә була.

P.S. *Зыяны булырга мөмкин. Алдан табиб белән киңәшләшү сорала. Язма массажны күренеш буларак тасвирлау максатыннан язылды.*

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6697 данә
Гомуми тираж – 15337 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 373

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+